КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 1 ноябрь г.Казань № 1036

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында рискка юнәлдерелгән алым кулланыла торган төбәк дәүләт тикшерүе (күзәтчелеге) төрләре исемлеген раслау турында» 2018 ел, 27 сентябрь, 856 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасында рискка юнәлдерелгән алым кулланыла торган төбәк дәүләт тикшерүе (күзәтчелеге) төрләре исемлегенә үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында рискка юнәлдерелгән алым кулланыла торган төбәк дәүләт тикшерүе (күзәтчелеге) төрләре исемлеген раслау турында» 2018 ел, 27 сентябрь, 856 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 ел, 15 апрель, 287 нче; 2020 ел, 5 август, 652 нче; 2020 ел, 1 декабрь, 1081 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасында рискка юнәлдерелгән алым кулланыла торган төбәк дәүләт тикшерүе (күзәтчелеге) төрләре исемлегенә, аны яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итеп, үзгәреш кертергә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2018 ел, 27 сентябрь, 856 нчы
карары белән расланды
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2021 ел, 1 ноябрь, 1036 нчы
карары редакциясендә)

Татарстан Республикасында рискка юнәлдерелгән алым кулланыла торган төбәк дәүләт тикшерүе (күзәтчелеге) төрләре
исемлеге

| Т/с | Төбәк дәүләт тикшерүе (күзәтчелеге) төренең исеме |
|---|---|
| 1. | Күпфатирлы йортлар белән идарә итү буенча эшмәкәрлек эшчәнлегенә лицензия контроле |
| 2. | Алкогольле продукцияне ваклап сатуга лицензия контроле |
| 3. | Халыкны һәм территорияләрне төбәк, муниципальара һәм муниципаль характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау өлкәсендә төбәк дәүләт күзәтчелеге |
| 4. | Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан төбәк әһәмиятендәге мәдәни мирас объектларының, җирле (муниципаль) әһәмияттәге мәдәни мирас объектларының, ачыкланган мәдәни мирас объектларының торышы, аларны карап тоту, саклау, куллану, популярлаштыру һәм дәүләт тарафыннан саклауга төбәк дәүләт күзәтчелеге |
| 5. | Үзйөрешле машиналар һәм техниканың башка төрләре, аттракционнарның техник торышы һәм эксплуатациясе өлкәсендә төбәк дәүләт күзәтчелеге |

_______________________________